МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.06.2022 Казан ш. № 389-пр

Татарстан Республикасы
милкендә булган мөлкәтне
исәптән чыгару тәртибе турында

Дәүләт милкендә булган мөлкәтне исәптән чыгару, исәптән чыгару буенча карарлар кабул иткәндә хәбәрдарлык һәм ачыклыкны тәэмин итү һәм дәүләт милкен куллану нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләрен тәртипкә салу максатларында б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне исәптән чыгару тәртибе турында тәкъдим ителгән нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының түбәндәге карарларын көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы милкендә булган объектларның туктатылган яки (һәм) гамәлгә ашырылмаган төзелеше буенча чыгымнарны һәм төп фондларны исәптән чыгару тәртибе турында” 17.03.2004 № 380-р;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 17.03.2004 № 380-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган объектларның туктатылган яки (һәм) гамәлгә ашырылмаган төзелеше буенча чыгымнарны һәм төп фондларны исәптән чыгару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” 24.02.2005 № 158-р;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 17.03.2004 № 380-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган объектларның туктатылган яки (һәм) гамәлгә ашырылмаган төзелеше буенча чыгымнарны һәм төп фондларны исәптән чыгару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” 23.12.2005 № 1840-р;

“Татарстан Республикасы милкендә булган объектларның туктатылган яки (һәм) гамәлгә ашырылмаган төзелеше буенча чыгымнарны һәм төп фондларны исәптән чыгару тәртибе турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 17.03.2004 № 380-р карарына үзгәрешләр кертү турында” 23.11.2009 № 2523-р;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 17.03.2004 № 380-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган объектларның туктатылган яки (һәм) гамәлгә ашырылмаган төзелеше буенча чыгымнарны һәм төп фондларны исәптән чыгару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” 08.04.2010 № 884-р;

“Татарстан Республикасы милкендә булган объектларның туктатылган яки (һәм) гамәлгә ашырылмаган төзелеше буенча чыгымнарны һәм төп фондларны исәптән чыгару тәртибе турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 17.03.2004 № 380-р карарына үзгәрешләр кертү турында” 16.02.2012 № 393-р.

3. Хокук идарәсенә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында әлеге боерыкка дәүләт регистрациясе үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
22.06.2022 № 386-пр
боерыгы белән расланды

-

**Татарстан Республикасы**
**милкендә булган мөлкәтне**
**исәптән чыгару тәртибе турында**
**нигезләмә**

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне исәптән чыгару тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, Шәһәр төзелеше кодексы, «Дәүләти һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге № 161-ФЗ, «Автоном учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге № 174-ФЗ, «Бухгалтер учеты турында» 2011 елның 6 декабрендәге № 402-ФЗ федераль законнар, Россия Федерациясенең «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы № 4979-1 законы, Россия Федерациясе Финанслар министрлыгының 2010 елның 1 декабрендәге № 157н боерыгы белән расланган Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, дәүләти бюджеттан тыш фондлар белән идарә органнары, дәүләти фәннәр академияләре, дәүләти (муниципаль) учреждениеләр өчен бухгалтер учеты исәп-хисабының бердәм планы һәм Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, дәүләти бюджеттан тыш фондлар белән идарә органнары, дәүләти фәннәр академияләре, дәүләти (муниципаль) учреждениеләр өчен бухгалтер учеты исәп-хисабының бердәм планын файдалану буенча инструкция, Россия Федерациясе Финанслар министрлыгының « «Төп чаралар» дәүләт секторы оешмалары өчен бухгалтер учеты федераль станлартын раслау турында» 2016 елның 31 декабрендәге № 257н боерыгы, «Дәүләти (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерү белән бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.05.2010 № 83-ФЗ Федераль Законны Татарстан Республикасындагы дәүләт учреждениеләрен булдыру, үзгәртеп оештыру, төрен үзгәртү һәм бетерү ягыннан тәртип урнаштыру, шулай ук, Татарстан Республикасындагы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючының һәм

мөлкәт иясенең функцияләрен һәм вәкаләтләрен регламентацияләү ягыннан Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.10.2010 № 820 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турында нигезләмәне раслау турында» 30.08.2014 № 628 карарын (алга таба - ТР МК карары 30.08.2014 № 628) искә алып әзерләнде.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы милкендә булган түбәндәге мөлкәтне (алга таба – исәптән чыгару объекты) исәптән чыгарганда килеп чыккан мөнәсәбәтләрне көйли:

Татарстан Республикасы казнасы составына кергән;

Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, дәүләт унитар предприятиеләренә, автоном, бюджет һәм казна учреждениеләренә хуҗалык итү яки оператив идарә хокукында беркетелгән;

хуҗалык итү яки оператив идарә хокукында беркетелмәгән мөлкәткә мөнәсәбәтле эш итү һәм (яки) файдалану хокуклары күчүне күздә тоткан аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, мөлкәт белән ышанып идарә итү шартнамәсе, җаваплы саклау шартнамәсе һәм башка шартнамәләр буенча бирелгән

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

мөлкәтне исәптән чыгару – мөлкәтне максатчан билгеләнеш буенча алга таба куллану һәм (яки) түбәндәге сәбәпләр буенча эш итү өчен яраксыз дип тану белән бәйле гамәлләр комплексы:

куллану үзенчәлекләрен тулысынча яки өлешчә югалту, шул исәптән, физик яисә мораль тузу;

үлеме яки юк ителүе, җитешмәүчелек яки урлану (хокук саклау органнары, янгын күзәтчелеге органнары һәм башка вәкаләтле органнарның документаль раславы белән) аркасында биләмәләрдән, кулланылыштан һәм кул астыннан чыгуы;

исәптән чыгару объектының урынын билгеләү мөмкин түгеллек (техник инвентаризация органының документаль раславы белән);

күчемсез милек объектының яңа төзелеш яки булган объектны реконструкцияләү планлаштырылган җир кишәрлегендә урнашуы;

субъект – оператив идарә хокукында мөлкәт беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе (казна, бюджет, автоном) һәм Татарстан Республикасы казна

предприятиесе; хуҗалык алып бару хокукыда мөлкәт беркетелгәнгән дәүләт унитар предприятиесе;

мөлкәтне кулланучы – Татарстан Республикасы милкендә булган, хуҗалык итү яки оператив идарә хокукында беркетелмәгән мөлкәткә мөнәсәбәтле эш итү һәм (яки) файдалану хокуклары күчүне күздә тоткан файдалану өчен аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, мөлкәт белән ышанып идарә итү шартнамәсе, җаваплы саклау шартнамәсе һәм башка шартнамәләр буенча мөлкәт беркетелгән юридик зат;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы – мөлкәт иясе исеменнән эш итүче һәм мөлкәт белән эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының башкарма хакимият органы;

Комиссия – мөлкәтне исәптән чыгару буенча субъект (мөлкәтне кулланучы) гамәлгә куйган комиссия;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының исәптән чыгару буенча комиссиясе – мөлкәтне исәптән чыгару мәсьләләрен карау һәм карар кабул итү максатларында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында оештырылган мөлкәтне исәптән чыгару буенча даими эшләүче комиссия;

мөлкәтне исәптән чыгару турында акт – исәптән чыгарылган мөлкәтнең төренә карап форма буенча төзелгән акт (Россия Федерациясе Госкомстатның «Төп чараларны исәпкә алу буенча беренчел учет документациясенең унификацияләнгән формаларын раслау турында» 2003 елның 21 гыйнварындагы № 7 карары белән расланган унификацияләнгән формалар);

Комиссия беркетмәсе – субъект (мөлкәтне кулланучы) оештырган мөлкәтне исәптән чыгару буенча комиссия утырышы йомгаклары буенча әзерләнгән документ;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгынең исәптән чыгару буенча комиссиясе беркетмәсе – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы оештырган мөлкәтне исәптән чыгару буенча даими комиссия утырышы йомгаклары буенча әзерләнгән, килештерү турында карара яки мөлкәтне исәптән чыгаруны килештерүдән баш тарту каралган документ;

исәптән чыгару турында карар – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының Татарстан Республикасы казнасы составына кертелгән мөлкәтне исәптән чыгару турында карары;

исәптән чыгаруны килештерү турында карар - хуҗалык итү яки оператив идарә хокукында беркетелмәгән мөлкәткә мөнәсәбәтле эш итү һәм (яки) файдалану хокуклары күчүне күздә тоткан файдалану өчен аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, мөлкәт белән ышанып идарә итү шартнамәсе,

җаваплы саклау шартнамәсе һәм башка шартнамәләр буенча мөлкәт беркетелгән мөлкәтне исәптән чыгаруны килештерү турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карары;

капиталь төзелеш объектлары – бина, корылма, каралты, төзелеп бетмәгән объектлар, чыгарылма булып капиталь булмаган корылмалар, каралтылар һәм җир кишәрлеген яхшырту (томалау, каплау һәм башкалар);

торак-коммуналь хуҗалык объектлары – торак-коммуналь хезмәт күрсәтү процессын гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән корылмалар, инженерлык коммуникацияләре, производство циклы биналары һәм технологик звенолар.

1.3. Әлеге Нигезләмәнең көче Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы килештерүеннән башка гамәлгә ашырылган мөлкәтне исәптән чыгаруга карармый, аерым алганда:

дәүләт китапханә фонды;

«матди булмаган активлар» статьясы буенча тулы булмаган хокуклы программа продуктлары;

күчемле милек, беренчел бәясе 100 000 сум һәм аңа кадәр булган транспорт чараларыннан башка.

Указанное имущество списывается субъект тарафыннан субъектны гамәлгә куючы белән килештерелеп, субъектны гамәлгә куючыга тиешле тәртиптә гамәлдән чыгарылу турында актлар тапшырылып исәптән чыгарыла.

1.4. Әлеге Нигезләмәнең көче мәдәни мирас обектларын исәптән чыгаруга карамый, аларның хокукы нигезләре исәптән чыгаруның башка тәртибен билгеләүче «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкәрьләре) турында», 2002 елның 25 июнь № 73-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның № 60-ЗРТ Татарстан Республикасы законы һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән көйләнә.

1.5. Әлеге Нигезләмәнең көче Татарстан Республикасы бюджеты белән финансланган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты белән финансланган, туктатылган төзелеш объектлары һәм (яки) туктатылган төзелеш объектлары чыгымнарын дәүләт заказчылары тарафыннан исәптән чыгару тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында” 11.02.2020 № 91 карары нигезендә исәптән чыгарыла торган туктатылган төзелеш объектлары һәм (яки) туктатылган төзелеш объектлары чыгымнарын дәүләт заказчылары тарафыннан исәптән чыгаруга карамый,

## 2. Исәптән чыгару шартлары

2.1. Мөлкәтне, шул исәптән транспорт чараларын, исәптән чыгару турында карар (исәптән чыгаруны килештерү турында карар) андый мөлкәт түбәндәге шартларда булганда кабул ителә:

куллану үзенчәлекләрен тулысынча яки өлешчә югалтып алга таба максатчан куллану өчен яраксыз булса, шул исәптән, физик яки мораль искерү;

үлеме яки юк ителүе, җитешмәүчелек яки урлану аркасында биләмәләрдән, кулланылыштан һәм кул астыннан чыккан (хокук саклау органнары, янгын күзәтчелеге органнары һәм башка вәкаләтле органнарның документаль раславы белән);

күчемсез милек объекты (туктатылган төзелеш объектларын кертеп) яңа төзелеш яки булган объектны реконструкцияләү планлаштырылган җир кишәрлегендә урнашкан һәм исәптән чыгару объекты төзелеш зонасына эләгә;

исәптән чыгару объектының урынын билгеләү мөмкин түгел.

2.2. Алга таба эксплуатацияләү өчен яраклы мөлкәтнең үз бәясенең 100 проценты күләмендә амортизациясе мөлкәтне исәптән чыгару өчен нигез булып тормый.

2.3. Инвентаризация нәтиҗәсендә җитешмәүчелеге ачыкланган мөлкәтне исәптән чыгару гаепле кеше тарафыннан аның бәясе түләнгәч башкарыла, законнар буенча андый түләү мөмкин булмаган очраклар чыгарылма булып тора.

2.4. Сакларга бирелгән мөлкәт бозылса яки югалса, саклаучы исәптән чыгарыла торган объектның бәясен түләсә исәптән чыгарыла.

2.5. Исәптән чыгарыла торган объектны исәптән чыгару турында карарны (исәптән чыгаруны килештерү турында карар) алмыйча торып сүтергә, демонтаж ясарга һәм утлизацияләргә рөхсәт ителми.

## 3. Мөлкәтне исәптән чыгару тармагында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының вәкаләтләре

3.1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы түбәндәгеләрне кабул итә:

Татарстан Республикасы казнасы составына кергән мөлкәтне исәптән чыгарганда исәптән чыгару турында карар;

хуҗалык итү яки оператив идарә хокукында беркетелгән, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, мөлкәт белән ышанып идарә итү шартнамәсе, җаваплы саклау шартнамәсе һәм башка шартнамәләр буенча

кулланучыга бирелгән мөлкәтне исәптән чыгарганда исәптән чыгаруны килештерү турында карар.

3.2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының исәптән чыгару буенча комиссиясе беркетмәсе нигезендә түбәндгеләргә мөнәсәбәтле карар кабул итә:

күчемсез милек, туктатылган төзелеш объектлары, беренчел бәясенә карамастан;

транспорт чаралары, беренчел бәясенә карамастан;

күчемле милек, инвентарь берәмлегенә беренчел бәясе 100 000 сумнан арткан очракта;

күчемле, шул исәптән, транспорт чаралары, һәм күчемсез милек, мөлкәткә мөнәсәбәтле биләү һәм (яисә) файдалану хокуклары күздә тотылган, беренчел бәясенә карамастан хуҗалык итү яки оператив идарә хокукында беркетелмәгән, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, мөлкәт белән ышанып идарә итү шартнамәсе, җаваплы саклау шартнамәсе һәм башка шартнамәләр буенча бирелгән;

Татарстан Республикасы территориясендә кулланылмаган хайван күмү урыннарын (биотермик чокырлар) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы территориясендә кулланылмаган хайван күмү урыннарын (биотермик чокырлар) ликвидацияләү тәртибен раслау турында" 06.05.2017 № 263 карарына (алга таба - 06.05.2017 № 263 ТР МК карары) туры китереп һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсеннән юлланган язмача мөрәҗәгать нигезендә;

беренчел бәясенә карамастан, тулы хокуклы матди булмаган активларны.

## 4. Татарстан Республикасының дәүләт учреждениесенә (автоном, бюджет, казна) беркетелгән мөлкәтне исәптән чыгару

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесенә (автоном, бюджет, казна) оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәтне исәптән чыгару субъект тарафыннан түбәндәгеләргә мөнәсәбәттә гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан тыш, гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимият органы ризалыгы булганда исәптән чыгаруны килештерү турында күрсәтмә нигезендә күчемсез милеккә, транспорт чараларына һәм аларның беренчел бәясенә бәйсез рәвештә аерым хокуклы материаль булмаган активларга һәм

инвентарь берәмлеге өчен беренчел бәясе 100 000 сумнан артык булган күчемле милеккә;

закон нигезендә мөстәкыйль рәвештә инвентарь берәмлеге өчен беренчел бәясе 100 000 сумга кадәр булган күчемле милеккә.

## 5. Татарстан Республикасының дәүләт унитаным предприятиесенә беркетелгән мөлкәтне исәптән чыгару

Дәүләт унитар предприятиесенә хуҗалык алып бару (оператив идарә итү) хокукында беркетелгән мөлкәтне исәптән чыгару субъект тарафыннан түбәндәгеләргә мөнәсәбәттә гамәлгә ашырыла:

дәүләт унитар предприятиесе карамагында булган башкарма хакимият органы ризалыгы булган очракта исәптән чыгаруны килештерү турында күрсәтмә нигезендә күчемсез милеккә, транспорт чараларына һәм аларның беренчел бәясенә бәйсез рәвештә аерым хокуклы материаль булмаган активларга һәм инвентарь берәмлеге өчен беренчел бәясе 100 000 сумнан артык булган күчемле милеккә;

закон нигезендә мөстәкыйль рәвештә инвентарь берәмлеге өчен беренчел бәясе 100 000 сумга кадәр булган күчемле милеккә.

## 6. Татарстан Республикасы казнасы составына кертелгән мөлкәтне исәптән чыгару

Татарстан Республикасы казнасы составына кертелгән тузган яки авария хәленә килгән мөлкәтне исәптән чыгаруны күчемсез һәм күчемле милеккә, шул исәптән транспорт чараларына карата, шулай ук исәптән чыгару турында Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан кабул ителгән боерык нигезендә инвентарь берәмлеге өчен беренчел бәясенә бәйсез рәвештә аеруча хокуклы булган матди булмаган активларга карата Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы яки Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы йөкләмәсе буенча «Республика мөлкәт казнасы» ДБУ ведомство карамагындагы оешма гамәлгә ашыра.

## 7. Аренда килешүе, түләүсез файдалану килешүе, милеккә ышаныч белән идарә итү шартнамәсе һәм хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында беркетелмәгән мөлкәткә карата ия булу һәм (яки) файдалану хокукларын күчерүне күздә тоткан бүтән шартнамәләр буенча тапшырылган мөлкәтне исәптән чыгару

Мөлкәтне кулланучыга аренда килешүе, түләүсез файдалану килешүе, милеккә ышаныч белән идарә итү шартнамәсе һәм хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында беркетелмәгән мөлкәткә карата ия булу һәм (яки) файдалану хокукларын күчерүне күздә тоткан бүтән шартнамәләр буенча тапшырылган мөлкәтне исәптән чыгару күчемле һәм күчемсез мөлкәткә, шул исәптән транспорт чараларына, шулай ук инвентарь бирәмлеге өчен беренчел бәясенә бәйсез рәвештә аерым хокуклы матди булмаган активларга карата Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы чыгарган исәптән төшерүне килештерү турындагы боерык нигезендә мөлкәтне кулланучы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 8. Комиссия вәкаләтләре

Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

исәп-хисап-техник һәм башка документлардагы мәгълүматларны исәпкә алып, исәптән чыгаруга планлаштырыла торган мөлкәтне тикшерә;

мөлкәтне алга таба куллануның максатка ярашлылыгы (яраклылыгы), аны торгызу мөмкинлеге һәм нәтиҗәлелеге, милекнең аерым өлешләрен, конструкцияләрен һәм материалларын куллану мөмкинлеге турындагы мәсьәлә буенча карар кабул итә;

милекне исәптән чыгару кирәклегенә китергән сәбәпләрне билгели;

исәптән чыгару объектының техник торышы турында, аны киләчәктә файдаланып булмау һәм (яки) торгызуның максатка ярашлы булмавы сәбәпләрен күрсәтеп, бәяләмә әзерли;

милекне исәптән чыгару турында акт әзерли;

әлеге Нигезләмәнең 10 бүлеге нигезендә документлар пакетын формалаштыра.

## 9. Комиссиянең составы һәм эш тәртибе

9.1. Комиссия Комиссия рәисеннән һәм әгъзаларыннан тора. Комиссияне субъект (мөлкәтне кулланучы) җитәкчесе яки җитәкче урынбасары җитәкли.

9.2. Комиссия составына керә:

баш бухгалтер яисә аның урынбасары (штат расписаниесе белән баш бухгалтер вазыйфасы каралмаган субъектлар һәм мөлкәтне кулланучылар өчен - бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән зат);

материаль кыйммәтләрне саклау өчен җаваплылык йөкләнгән зат;

исәптән чыгару объектының үзенчәлегенә карап башка вазыйфаи затлар;

исәптән чыгару объектының үзенчәлегенә карап, җәлеп ителә торган башка белгечләр (алар ризалыгы белән).

9.3. Комиссия карары утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия карары Комиссия беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Комиссия әгъзалары субъект җитәкчесе (мөлкәтне кулланучы җитәкчесе) тарафыннанраслана торган милекне карау актына кул куялар.

Карау актына мәҗбүри рәвештә исәптән чыгару объектының торышы (милекнең алга таба файдалануга яраксызлыгы, аны торгызуның мөмкин булмавы яки нәтиҗәсез булуы) турында мәгълүмат кертелә.

Карау акты, актны төзү датасын һәм субъект җитәкчесе (мөлкәтне кулланучы җитәкчесе) тарафыннан раслану датасын күрсәтеп, субъектның (мөлкәтне кулланучы) мөһере белән раслана.

## 10. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына субъект (мөлкәтне кулланучы) тапшыра торган документлар

10.1. Исәптән чыгаруны килештерү турында боерык алу өчен субъект (мөлкәтне кулланучы) Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы адресына түбәндәге документларны тапшыра:

исәптән чыгару сәбәбен күрсәтеп, милекне исәптән чыгару кирәклеге турында язма мөрәҗәгать;

билгеләнгән тәртиптә расланган Комиссия төзү турында субъект (мөлкәтне кулланучы) җитәкчесе боерыгы күчермәсе;

Комиссия беркетмәсе күчермәсе;

субъектны (мөлкәтне кулланучыны) гамәлгә куючының мөлкәтне исәптән чыгаруга ризалыгы. Күрсәтелгән таләп Татарстан Республикасы дәүләт органнарына тапшырылган мөлкәтне исәптән чыгаруга кагылмый;

күзәтчелек советы беркетмәсе (автоном учреждениеләр өчен);

фотоматериаллар (исәптән чыгару объектын идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган язулы, төсле);

исәптән чыгарыла торган мөлкәт төренә карап, исәптән чыгару (утильләштерү) турында субъект җитәкчесе (мөлкәтне кулланучы) тарафыннан расланган һәм мөһер белән таныкланган, вакыты 3 айдан артмаган акт;

исәптән чыгару объектының техник торышы турында Комиссия бәяләмәсе, аны алга таба файдалану мөмкин булмавы һәм (яки) яңадан торгызуның максатка ярашсызлыгы сәбәпләрен күрсәтеп (субъект (мөлкәтне кулланучы) штатында кирәкле квалификация белгечләре булганда);

җиһазларга, оргтехникага, башка күчемле милеккә хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау белән шөгыльләнүче махсуслаштырылган оешманың исәптән чыгару объектын алга таба файдалану яраксызлыгын раслаучы бәяләмәсе (субъект (мөлкәтне кулланучы) штатында кирәкле квалификация белгечләре булмаганда);

лицензияләр яки туры килү сертификаты күчермәләре, исәптән чыгару объектының алга таба файдалануга яраксызлыгы турында бәяләмә биргән оешма раслаган бүтән документлар;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.08.2014 елның 30 августындагы 628 номерлы карары нигезендә төзелгән исәпкә алу материаллары, шул исәптән электрон формада.

10.2. Өстәмә рәвештә бирелә:

а) транспорт чараларын һәм үзйөрешле машиналарны исәптән чыгарганда:

техник һәм транспорт чараларын теркәү паспортлары һәм таныклыклары күчермәләре;

б) аварияләр нәтиҗәсендә яраксызлыкка килгән транспорт чараларын исәптән чыгарганда:

юл-транспорт һәлакәте турында акт;

тикшерү органнарының җинаять эшен кузгату яки туктату турында карары (булганда);

милеккә зыян китерүче гаепле затларга карата кабул ителгән чаралар турында субъект җитәкчесенең хаты;

гаепле затларның зыянны каплаулары турында субъект (мөлкәтне кулланучы) белешмәсе;

в) күчемсез милек объектларын исәптән чыгарганда:

исәптән чыгарылырга тиешле күчемсез милек объектына хокук билгеләүче документ күчермәсе (оператив идарә итү хокукы турында таныклык яисә күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә);

техник исәпкә алу документларының күчермәләре (исәптән чыгарылырга тиешле күчемсез милек объектына кадастр һәм техник паспорт, этажлар планы, экспликация) (булган очракта);

исәптән чыгарылырга тиешле күчемсез милек объекты булган җир кишәрлегенә хокук билгеләүче документның күчермәсе (Татарстан Республикасы милкенә хокук турында таныклык яисә күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә);

исәптән чыгарылырга тиешле күчемсез милек объектының конструктив элементларының техник торышы һәм аны киләчәктә файдалана алмау турында махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе (субъектның (мөлкәтне кулланучы) штатында тиешле квалификация белгечләре булмаганда);

исәптән чыгарылырга тиешле күчемсез милек объектын сүтү (демонтаж) буенча эшләрнең чыганаклары һәм финанслау сроклары турында белешмә (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 6.4 бүлеге нигезендә, күчемсез милек объектын сүтү (демонтажлау) подрядчы оешма тарафыннан капиталь төзелеш объектын сүтүне оештыру проекты нигезендә башкарыла);

г) яңа объект төзелеше белән бәйле рәвештә күчемсез милек объектларын исәптән чыгарганда:

яңа төзелеш объектының килештерелгән (расланган) проект документлары, шул исәптән җир кишәрлеген планлаштыруны оештыру схемасы;

д) торак биналарны, шул исәптән тулай торакларны исәптән чыгарганда:

күчемсез милек объектын исәптән чыгару зарурлыгын һәм нигезлелеген раслаучы документлар (Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарын бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия тарафыннан торакны торак урыны дип, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм үпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы «Торакны торак урыны дип, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип, бакча йортын торак йорт дип һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 47 номерлы карары нигезендә форма буенча бәяләмә);

исәптән чыгарыла торган күчемсез милек объектында яшәүчеләр булмау турында теркәү органнарыннан белешмә;

е) торак-коммуналь хуҗалык объектларын исәптән чыгарганда:

исәптән чыгару кирәклеген һәм нигезлелеген раслаучы документлар;

торак-коммуналь хуҗалык объектында кулланучылар юклыгы турында челтәр оешмасыннан (җылылык-су-энергия белән тәэмин итүче оешмалар) белешмә;

ж) яшь терлекләрдән һәм суяр өчен каралган терлекләрдән кала, эшче терлекләрне исәптән чыгарганда (атлар, дөяләр, ишәкләр һәм башка эшче терлекләр):

ярып карау акты (хайван үлгәндә) йә хайванны яраксызга чыгаруның сәбәбен һәм диагнозын күрсәтеп, хайванны яраксызга чыгару акты, шулай ук үлгән хайванның характеристикалары (ярып карау акты документны төзүнең дөреслеге һәм эчтәлеге өчен шәхси җаваплылыгы булган ветеринария табибы тарафыннан төзелә; акт Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана);

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнардан яки оешмалардан хайванүлеме яки аларны юкка чыгару турында белешмә.

Бу очракта Комиссиягә ветеринария табибы кертелә;

з) тәмамланмаган төзелеш объектларын һәм (яки) тәмамланмаган төзелеш объектларына чыгымнарны исәптән чыгарганда:

күчемсез милек объекты төзелешен туктату турында акт;

гамәлгә ашырылмаган төзелеш буенча проект-тикшеренү эшләрен туктатып тору турында акт;

башкарылган эшләрне кабул итү һәм башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның бәясе турында актлар;

тәмамланмаган төзелеш объекты гамәлдәге бурыч булмавы турында мәгълүмат;

тәмамланмаган төзелеш объекты фотолары;

тәмамланмаган төзелеш объектын техник тикшерү акты һәм аның техник торышы турында белешмә;

төзелеш өчен җир кишәрлеге бирү турында документлар;

тәмамланмаган төзелеш объектына табигый бәла-казалар, янгын нәтиҗәсендә авария, югалу яки зыян килү (җимерелү) турындагы актларның күчермәләре;

тәмамланмаган төзелеш объекты буенча чыгымнар исемлеге;

Чыгымнарны бетерү сәбәпләре нигезләнгән белешмә;

и) аварияләр, табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә файдалануга яраксыз хәлгә килгән мөлкәтне исәптән чыгарганда:

авария, бозу һәм башка гадәттән тыш хәлләр турында тиешле дәүләт органы тарафыннан бирелгән акт күчермәсе;

җинаять эшен туктату турындагы карарның күчермәсе йә җинаять эшен кузгатудан баш тарту турындагы карар күчермәсе, йә административ хокук бозу турындагы хокук саклау органнары тарафыннан бирелгән карарның (беркетмәнең) күчермәсе;

табигый бәла-казалар яки башка гадәттән тыш хәлләр очрагында - китерелгән зыян турында акт, тиешле органнар яки гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр хезмәтләренең, янгынга каршы һәм башка махсус хезмәтләрнең табигый бәла-казалар яки башка гадәттән тыш хәлләр фактын раслаучы белешмәләре;

субъектның (мөлкәтне кулланучының) китерелгән зыян бәясе турында белешмәсе;

к) аерым хокуклы матди булмаган активларны исәптән чыгарганда:

субъектның (мөлкәтне кулланучының) объектны сәбәбен күрсәтен куллануны туктату турындагы документы.

10.3. Тапшырыла торган документларда эчтәлекне дөрес аңларга комачаулый торган бозылган урыннар, төзәтмәләр булу рөхсәт ителми.

### 11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 6 маендагы 263 номерлы карары (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 6 маендагы 263 номерлы карары) нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә кулланылмый торган үләт базларын (биотермик чокырларны) исәптән чыгарганда (юкка чыгарганда) Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бирелә торган документлар

11.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 6 маендагы 263 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә кулланылмый торган үләт базларын (биотермик чокырларны) гамәлдән чыгарганда Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына җибәрелә:

Ветеринария идарәсенең кулланылмый торган үләт базларын (биотермик чокырларны) бетерү (юкка чыгару) кирәклеге турында язма мөрәҗәгате;

Татарстан Республикасы милкендә булган файдаланылмый торган үләт базларын (биотермик чокырны) эпизоотологик тикшерү буенча комиссия төзү турында Ветеринария идарәсенең хокукый актының күчермәсе;

юкка чыгарылырга тиешле кулланылмый торган үләт базлары (биотермик чокырлар) реестрыннан өземтә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 6 маендагы 263 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә кулланылмый торган үләт базларын (биотермик чокырларны) бетерү тәртибенә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча файдаланылмый торган үләт базын (биотермик чокырны) лаборатор-бактериологик тикшерү нәтиҗәләре белән кулланылмый торган үләт базларын (биотермик чокырларны) эпизоотологик тикшерү акты;

11.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 6 маендагы 263 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә кулланылмый торган үләт базларын (биотермик чокырларны) бетерү тәртибенең 4.1 пунктында каралган документлар кергән көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы Татарстан Республикасы милкендә булган файдаланылмый торган үләт базын (биотермик чокырны) исәптән чыгару турында яисә исәптән чыгарудан баш тарту турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының исәптән чыгару комиссиясе беркетмәсе нигезендә әзерләнгән күрсәтмә чыгара.

## 12.Мөлкәтне мөстәкыйль исәптән чыгаруны күздә тоткан очракларда субъект тарафыннан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшырыла торган документлар

Субъект тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 1 бүлегендәге 1.3 пунктында каралган очракларда мөлкәтне исәптән чыгарганда Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшырыла:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 августындагы 628 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына тиешле үзгәрешләр кертү өчен кирәкле исәп материаллары.

## 13. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында мөлкәтне исәптән чыгару (исәптән чыгаруны килештерү) турында карар кабул итү тәртибе

13.1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында мөлкәтне исәптән чыгару (исәптән чыгаруны килештерү)

турындагы мәсьәләләрне карау һәм карар кабул итү Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының исәптән чыгару комиссиясе тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының исәптән чыгару комиссиясе исәптән чыгару өчен тәкъдим ителгән мөлкәткә карата хокуклы:

әлеге Нигезләмәнең 3 нче бүлеге нигезендә алга таба файдалануның мөмкин булмавы яки аны киләчәктә файдалануның максатка ярашлы булмавы сәбәпле милекне исәптән чыгару турында карар кабул итәргә;

исәптән чыгаруга тәкъдим ителгән мөлкәтне читләштерү турында тәкъдим кертергә;

исәптән чыгаруга тәкъдим ителгән мөлкәтне юридик затка килешү буенча түләүсез файдалануга, ышанычлы идарәгә яки арендага бирү турында тәкъдим кертергә;

исәптән чыгаруга тәкъдим ителгән мөлкәтне оператив идарә хокукында яисә хуҗалык алып бару хокукында башка субъектка (мөлкәтне кулланучыга) беркетү турында тәкъдим кертергә;

исәптән чыгаруга тәкъдим ителгән кулланылмый торган мөлкәтне Татарстан Республикасы казнасына кертү турында карар кабул итәргә.

13.2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының исәптән чыгару комиссиясе:

документлар теркәлгәннән соң 30 көн эчендә милекне исәптән чыгару мәсьәләсе буенча тапшырылган документларны карый;

субъектка (мөлкәтне кулланучыга) өстәмә документлар бирү турында (кирәк булганда) хәбәр итә, шул ук вакытта яңадан кергән документларны карау теркәлгәннән соң 30 көн эчендә башкарыла;

мөлкәтне исәптән чыгару турындагы мәсьәләне карый һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының исәптән чыгару комиссиясенең анда мөлкәтне исәптән чыгару (исәптән чыгаруны килештерү) турында карар яисә милекне исәптән чыгарудан (исәптән чыгаруны килештерү) баш тарту турындагы карар булган беркетмәсен төзи.

13.3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының исәптән чыгару комиссиясе беркетмәсе:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының исәптән чыгару комиссиясе рәисе (утырышта рәислек итүче), комиссия әгъзалары һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана;

утырыш датасыннан соң 7 көннән дә соңга калмыйча рәсмиләштерелә.

13.4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының исәптән чыгару комиссиясе беркетмәсе нигезендә исәптән чыгару турында (исәптән чыгаруны килештерү турында) ике нөсхәдә боерык чыгарыла.

13.5. Исәптән чыгару турындагы боерыкның (исәптән чыгаруны килештерү турындагы боерыкның) бер нөсхәсе субъектка (мөлкәтне кулланучыга) бирелә, икенче нөсхәсе Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы архивында саклана.

## 14. Мөлкәтне исәптән чыгарудан (исәптән чыгаруны килештерүдән) баш тарту өчен нигезләр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының исәптән чыгару комиссиясе түбәндәге очракларда мөлкәтне исәптән чыгарудан (исәптән чыгаруны килештерүдән) баш тарту турында карар кабул итә:

исәптән чыгаруга тәкъдим ителә торган мөлкәт әлеге Нигезләмәнең 3 бүлегендә күрсәтелгән мөлкәт категориясенә керми;

әгәр мөлкәтне исәптән чыгару технологик циклны бозуга китерсә;

исәптән чыгаруга тәкъдим ителә торган мөлкәттән башкача файдалану мөмкинлеге һәм (яки) максатчанлыгы бар (торги аша сату, тартып алу һәм законда билгеләнгән башка очраклар);

мөлкәтне исәптән чыгаруны килештерү өчен бирелгән документларны рәсмиләштергәндә хокук бозулар булганда яки тапшырылган документларда алдан ук мәгълүматларны дөрес бирмәү ачыкланганда;

әлеге Нигезләмәнең 10 бүлегендә күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын бирү;

исәптән чыгаруга тәкъдим ителә торган мөлкәтне исәптән чыгару өчен законнарда билгеләнгән чикләүләр булу;

субъектта (мөлкәтне кулланучыда) булган һәм исәптән чыгаруга тәкъдим ителә торган мөлкәткә арест салу яки исәп-хисап һәм башка счетларга арест салу;

арбитраж суды тарафыннан субъектны (мөлкәтне кулланучы) акчасыз (банкрот) дип тану, субъектны (мөлкәтне кулланучы) бетерү турында карар булу;

Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрында исәптән чыгаруга тәкъдим ителә торган мөлкәтнең булмавы;

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт мөлкәтен хуҗалык алып бару, оператив һәм ышанычлы идарә итү, җаваплы саклау, түләүсез файдалануга, арендага бирү турындагы карары булмау;

төбәктә экологик хәлне бозу куркынычы һәм законнарда каралган башка очракларда.

## 15. Мөлкәтне исәптән чыгару буенча чараларны үтәү тәртибе

15.1. Исәптән төшерүне килештерү турындагы боерык нигезендә субъект җитәкчеләре (мөлкәтне кулланучылар җитәкчеләре):

исәптән чыгару объектын сүтү һәм утильләштерү буенча мөстәкыйль рәвештә яки төзелгән килешү нигезендә өченче затларны җәлеп итеп чаралар үткәрәләр;

исәптән чыгару сәбәпле милекнең юкка чыгуын бухгалтерлык исәбендә чагылдыралар;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.08.2014 елның 30 августындагы 628 номерлы карары нигезендә, исәптән чыгару (утильләштерү) турында расланган актларны һәм Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына тиешле үзгәрешләр кертү өчен кирәкле исәп-хисап материалларын үз вакытында тапшыруны тәэмин итәләр;

түләүсез файдалану килешүенә, ышаныч идарәсе, аренда килешүләренә һәм хуҗалык алып бару хокукына яисә оператив идарә итү хокукына беркетелмәгән мөлкәткә карата ия булу хокукын һәм (яки) файдалану хокукын күчерүне күздә тоткан бүтән шартнамәләргә үзгәрешләр кертү турында өстәмә килешүләрне үз вакытында төзүне тәэмин итәләр.

15.2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләренә туры китереп мөлкәтне (капиталь төзелеш объектларын) исәптән чыгарганда мөлкәттән файдаланучылар (милекне кулланучылар) өстәмә рәвештә тәэмин итәләр:

капиталь төзелеш объектын – исәптән чыгару объектын сүтү буенча эшләрне оештыру проектын әзерләү;

җирле үзидарә органына исәптән чыгару объектын сүтү буенча эшләр башланганчы җиде эш көненнән дә соңга калмыйча планлаштырылган сүтү турында хәбәр бирү:

а) исәптән чыгару объектын тикшерү нәтиҗәләре һәм материаллары;

б) исәптән чыгару объектын сүтү буенча эшләрне оештыру проекты;

капиталь төзелеш объектын – исәптән чыгаруобъектын сүтү (демонтаж);

җирле үзидарә органына капиталь төзелеш объектын – исәптән чыгару объектын сүтү эшләрен тәгәлләгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча, исәптән төшерү объектын сүтү турында хәбәр бирү;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы адресына капиталь төзелеш объектын - исәптән чыгару объектын кадастр исәбеннән төшерү өчен XML – файл форматында техник инвентаризация органы тарафыннан әзерләнгән тикшерү актын тәкъдим итү.

15.3. Транспорт чараларын һәм үзйөрешле машиналарны исәптән чыгарганда субъектлар (мөлкәтне кулланучылар) өстәмә рәвештә:

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсендә яки Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсендә (мөлкәтне исәптән чыгару турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы боерыгы чыкканнан соң 1 айдан да артыграк булмаган вакыт эчендә) дәүләт теркәвеннән төшерү максатыннан транспорт чараларын һәм үзйөрешле машиналарны утильләштерүне тәэмин итәләр;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы адресына тапшыралар:

а) транспорт чараларын һәм үзйөрешле машиналарны дәүләт теркәве исәбеннән чыгару турында белешмәләр;

б) транспорт чараларын һәм үзйөрешле машиналарны – исәптән чыгару объектларын утильләштерү турында белешмәләр.

## 16. Мөлкәтне исәптән чыгаруны исәпкә алу үзенчәлекләре

16.1. Хуҗалык алып бару һәм оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәтне исәптән чыгару һәм утильләштерү (демонтажлау) буенча чараларга чыгымнар субъектлар акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

16.2. Татарстан Республикасы казнасына кертелгән мөлкәтне исәптән чыгару, демонтажлау һәм утильләштерү чараларына чыгымнар милекне кулланучылар хисабына гамәлгә ашырыла.

16.3. Мөлкәттән файдаланучылар булмаганда, Татарстан Республикасы казнасы составына кертелгән мөлкәтне исәптән чыгару, демонтажлау, утильләштерү чыгымнары шушы максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.

16.4. Субъект - дәүләт унитар предприятиесе балансындагы мөлкәтне исәптән чыгарудан килгән зыяннар хуҗалык эшчәнлегенең финанс нәтиҗәләренә карый, алар түбәндәге ысуллар белән каплана:

исәптән чыгару объектының беренче бәясенең үзләштерелми калган өлеше буенча чыгымнар хуҗалык эшчәнлегенең финанс нәтиҗәләренә карый;

төп фондлар бәясен яңадан бәяләүгә бәйле бәя артуның үзләштерелми калган өлеше буенча мөлкәтне түләүдән килгән зыяннар өстәмә капиталны киметүгә карый.

16.5. Субъект – дәүләт учреждениесе балансындагы мөлкәтне исәптән чыгарудан килгән зыяннар әлеге оешманы карап тотуга смета хисабына каплана.

16.6. Югалтулар суммасын исәпләгәндә, төзелеш корылмаларының кире кайтарыла торган материаллары (комплектлаштыру әйберләре) бәясе һәм материалларны сүтү, өеп кую, саклау белән бәйле чыгымнар исәпкә алына. Кирәкле очракларда биналарны, корылмаларны сүткәндә, җирле идарә органнары таләпләрен исәпкә алып, җирләрне рекультивацияләү үткәрелергә тиеш.

16.7. Кире кайтарыла торган материалларны сатудан һәм исәптән чыгару объектын металлоломга утильләштерүдән алынган табыш билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә:

казна учреждениеләренә тапшырылган мөлкәт;

аренда шартнамәсе буенча, түләүсез файдалану килешүе, милеккә ышаныч белән идарә итү шартнамәсе, җаваплы саклау шартнамәсе һәм хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында беркетелмәгән мөлкәткә ия булу һәм (яки) файдалану хокукларын күчерүне күздә тоткан бүтән килешүләр буенча тапшырылган мөлкәт.

16.8. Кире кайтарыла торган материалларны сатудан һәм исәптән чыгару объектын металлоломга утильләштерүдән алынган табыш исәптән чыгару вакытында мөстәкыйль күрсәтмәгә алына:

дәүләт бюджет һәм дәүләт автоном учреждениеләре тарафыннан оператив идарәдәге мөлкәт;

дәүләт унитар предприятиеләре тарафыннан хуҗалык карамагындагы мөлкәт.

## 17. ТР МК 2014 елның 30 августындагы 628 номерлы карары нигезендә исәптән чыгару объектын исәпкә алу тәртибе

Әлеге Нигезләмәнең 15 бүлегендә каралган чараларны тормышка ашыруны раслаучы тапшырылган документлар нигезендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы гамәлгә ашыра:

исәптән чыгару объектын Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрыннан төшереп калдыруны;

түләүсез файдалану килешүенә, ышаныч идарәсе шартнамәсенә, аренда килешүенә, җаваплы саклау шартнамәсенә тапшырылган милек составындагы үзгәрешләрне күздә тоткан үзгәрешләр кертү турында өстәмә килешү төзүне;

Татарстан Республикасы казнасы составына кертелгән мөлкәтне бухгалтерлык исәбеннән чыгаруны;

Татарстан Республикасы казнасы составына кертелгән мөлкәтне исәптән чыгару нәтиҗәсендә алынган яраклы детальләрне, өлешләрне, агрегатларны, материалларны Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрында исәпкә алу һәм аларны ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында бухгалтерлык исәбенә куюны.

## 18. Әлеге Нигезләмәне бозган өчен җаваплылык

18.1. Әлеге Нигезләмәне, дәүләт мөлкәтен исәптән чыгару тәртибен җайга сала торган башка норматив хокукый актларны бозып кылынган мөлкәтне исәптән чыгару гамәлдә түгел дип таныла, Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

18.2. ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшырылган белешмәләрнең һәм документларның актуальлеге һәм дөреслеге өчен субъектлар (мөлкәтне куллланучылар) җитәкчеләре җавап бирә.